СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 27 март Баулы шәһәре № 203

Баулы муниципаль районы
Советының 2018 елның 13
декабрендә кабул ителгән
188нче номерлы «Баулы муниципаль
районында муниципаль хезмәт
вакантлы вазыйфасын биләүгә
конкурс үткәрү тәртибе турында
нигезләмәне раслау хакында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартында кабул ителгән 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Баулы муниципаль районы Советының 2018 елның 13 декабрендә кабул ителгән 188нче номерлы «Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Конкурста катнашырга теләгән затлар конкурс комиссиясенә гариза бирәләр, аңа түбәндәге документлар беркетелергә тиеш:

1) муниципаль хезмәткә керү һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында үтенеч гаризасын;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны;

3) паспорт;

4) хезмәт кенәгәсе (хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелә торган очраклардан тыш);

5) белем турында документ;

6) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелә торган очраклардан тыш);

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары – запастагы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыру булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

10) муниципаль хезмәткә кергән ел алдыннан килгән елгы керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;

10.1) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче граждан, муниципаль хезмәткәрләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәркемгә ачык мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүмат урнаштырган сайтлар адреслары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүмат.

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советы Рәисе урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин